| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2025 п.г.т. Алексеевское № 527

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**спорт бүлеге турында**
**Нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча профилактика бүлеген үзгәртеп коруга бәйле рәвештә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге турында Нигезләмәне (Кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
_03.12.2025 ел,_ № _527_
карарына кушымта

**НИГЕЗЛӘМӘ**
**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Башкарма комитетының спорт бүлеге турында**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге (алга таба – Бүлек) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының (алга таба-Башкарма комитет) структур бүлекчәсе булып тора, физик культура һәм спортны үстерү өлкәсендә муниципаль идарә функцияләрен гамәлгә ашыра.

1.2. Бүлек Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә буйсына.

1.3. Бүлек үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Алексеевск муниципаль районы Башлыгы карарларына һәм күрсәтмәләренә, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Бүлек мәгариф бүлеге, опека һәм попечительлек бүлеге, яшьләр эшләре һәм туризм секторы, «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССО, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе, халыкны социаль яклау бүлеге һәм балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау чараларын гамәлгә ашыручы башка бүлекләр белән хезмәттәшлек итә.

1.5. Структурасы һәм штат расписаниесе Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан Башкарма комитет хезмәткәрләренең билгеләнгән саны һәм хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә раслана.

1.6. Бүлек ведомствосында 2 учреждение бар: Алексеевск районының «Спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе, Алексеевск районының «Кышкы спорт төрләре буенча спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе.

## 2. БҮЛЕКНЕҢ ТӨП БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Физик культураны һәм спортны үстерү, Алексеевск муниципаль районы халкының сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру. Шәхеснең гармонияле үсеше, яшьләрнең, шул исәптән үзешчән иҗатның физик үсеше өчен шартлар тудыру, сәләтле яшүсмерләрне һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү.

2.2. Алексеевск муниципаль районы халкын даими рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү.

2.3. Алексеевск муниципаль районы халкының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру, аларның социаль, көнкүреш һәм матди проблемаларын хәл итү өчен шартлар тудыру. Алексеевск муниципаль районы халкында әхлакый кыйммәтләр, патриотизм хисе, актив тормыш позициясе формалаштыру.

2.4. Балигъ булмаганнар һәм Алексеевск муниципаль районы халкы арасында күзәтүчесезлекне, хокук бозуларны, наркоманияне, алкоголизмны профилактикалау буенча системалы эш оештыру.

2.5. Социаль хәвеф-хәтәр төркеменә керүче күзәтүчесез һәм караучысыз балигъ булмаганнарны, шулай ук балигъ булмаганнарны карау, тәрбияләү һәм укыту бурычларын үтәмәүче йә аларның үз-үзләрен тотышына тискәре йогынты ясаучы балигъ булмаганнарның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) ачыклау һәм реабилитацияләү эшен оештыру.

2.6. Алексеевск муниципаль районы территориясендә физик культура һәм спорт объектларының матди-техник базасын үстерүне тәэмин итү.

2.7. Массакүләм мәгълүмат чараларын кулланып, Алексеевск муниципаль районы халкы арасында физик культураны, спортны һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

2.8. Районның мәдәни – тарихи мирасын саклау һәм пропагандалау.

2.9. Җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, халык сәнгать кәсепләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу.

## 3. БҮЛЕКНЕҢ ТӨП ФУНКЦИЯЛӘРЕ

Йөкләнгән бурычлар нигезендә бүлек түбәндәге функцияләрне башкара:

3.1. Үз компетенциясе чикләрендә ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тикшереп тора.

3.2. Алексеевск муниципаль районы территориясендә физик культура һәм спорт өлкәсендә озак сроклы максатчан программалар һәм проектлар эшли һәм гамәлгә ашыра, республика максатчан программаларын гамәлгә ашыруда катнаша.

3.3. Район спорт чараларын үткәрүне тәэмин итә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалый.

3.4. Ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрне үстерү өчен шартлар тудыра.

3.5. Билгеләнгән тәртиптә спортчыларга һәм тренерларга, физик культура хезмәткәрләренә спорт исемнәре бирү өчен документация тапшыра.

3.6. Бүлек эшчәнлеге юнәлешләре буенча бюджет формалаштыруда катнаша, бюджетның тиешле чыгымнарын планлаштыруны гамәлгә ашыра.

3.7. Физкультура-савыктыру, спорт оешмалары эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итә.

3.8. Алексеевск муниципаль районы халкы арасында спортны һәм физик культураны пропагандалау буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыра, массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдаланып, озак сроклы максатчан программаларны һәм проектларны мәгълүмати тәэмин итә.

3.9. Статистик мәгълүмат җыя, физик культура һәм спорт мәсьәләләре буенча исәп-хисапны оештыра һәм хисап бирүне оештыра.

3.10. Гамәлдәге законнар нигезендә башка функцияләрне башкара.

## 4. БҮЛЕКНЕҢ ХОКУКЛАРЫ

Бүлек үзенә йөкләнгән бурыч һәм функцияләр нигезендә хокуклы:

4.1. Үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә.

4.2. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары, авыл җирлекләре башлыклары каравына физик культура һәм спорт өлкәсендәге тәкъдимнәр кертергә.

4.3. Бүлек компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүматны учреждение, оешмалардан, ведомство карамагындагы булуларына карамастан, соратып алырга.

4.4. Бүлек карамагындагы учреждениеләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр кертергә.

4.5. Бүлек компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча консультация, киңәшмә, конференция, семинарлар уздырырга.

4.6. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәгълүмат базаларыннан файдаланырга.

4.7. Бүлеккә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан башка хокуклар һәм вәкаләтләр бирелергә мөмкин.

4.8. Балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча муниципаль органнарның, оешмаларның, барлык оештыру-хокукый рәвешләрнең һәм милек формаларының кирәкле мәгълүматларыннан файдаланырга.

## 5. БҮЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕН ОЕШТЫРУ

5.1. Бүлек җитәкчесе вазыйфага Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә.

5.2. Бүлек башлыгы:

- бүлек эшен оештыра, районда эшне координацияли һәм камилләштерә.
- бүлек белгечләре арасында вазыйфаларны әлеге Нигезләмә нигезендә бүлә;

- Башкарма комитет җитәкчесе һәм Алексеевск муниципаль районы Башлыгы карарларының, күрсәтмәләренең үтәлешен тикшереп тора.

- Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә бүлекнең башкарылган эше турында хисап бирә.

- Башкарма комитет Җитәкчесенә ведомство буйсынуындагы учреждениеләр һәм Башкарма комитетның спорт бүлеге вазыйфаларына кандидатураны раслау өчен тәкъдим итә.

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**